# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлегенең Бәли торак пунктындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**2023 ел 22 ноябрь** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 22 ноябрендәге 10 сәгать 00, 2023 елның 14 ноябрендәге 14 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплап җыеннары нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, “Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлегенең Бәли торак пункты территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?”:

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру*:

- җирлектэге торак пунктлардагы санкцияләнмәгән чүплекләрне чистарту;
- материаллар сатып алып балалар мәйданчыгын төзекләндерү;
- урам яктырткычларын ремонтлау, материаллар сатып алу;
- авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен тоту;

*б) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*

- зиратларны чистарту һәм ремонтлау, материаллар алу;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлекнең торак – пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

*г) авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- авыл җирлеге торак пунктларында материаллар сатып алып, су күтәрү манарасын тоту;
- авыл җирлеге торак пунктларында материаллар сатып алып сууткәргеч челтәрләрен ремонтлау;

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре беркетмәсе буенча:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 127 гражданнар җыенында катнашучылар кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 76 кеше, бу 56 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 76 "РИЗА" позициясе өчен, 0 "КАРШЫ" позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлегенең Бәли торак пунктындагы гражданнар җыенын үткән дип, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. "2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге Бәли торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган һәрбер кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру*:

- җирлектәге торак пунктлардагы санкцияләнмәгән чүплекләрне чистарту;
- материаллар сатып алып балалар мәйданчыгын төзекләндерү;
- урам яктырткычларын ремонтлау, материаллар сатып алу;
- авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрен тоту;

*б) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*

- зиратларны чистарту һәм ремонтлау, материаллар алу;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлекнең торак – пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

*г) авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- авыл җирлеге торак пунктларында материаллар сатып алып, су күтәрү манарасын тоту;
- авыл җирлеге торак пунктларында материаллар сатып алып суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Колаңгы авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Колаңгы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек
Колангы авыл жирлеге башлыгы итүче Ф.Т.Нигматзянов